КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 2 ноябрь г.Казань № 986

«Минем субсидияләр» мәгълүмат системасын булдыру турында

Дәүләт идарәсе, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә цифрлы технологияләрнең нәтиҗәле үсешен тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгының «Минем субсидияләр» мәгълүмат системасын (алга таба – Система) булдыру турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына:

Система турындагы нигезләмәне эшләргә һәм расларга;

Системаны формалаштыру һәм эшләтү буенча эшчәнлеккә методик җитәкчелек итүне һәм аны яраштыруны гамәлгә ашырырга.

3. «Татарстан Республикасының Цифрлы трансформацияләү үзәге» дәүләт казна учреждениесен Системаның операторы һәм дәүләт заказчысы итеп билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына, Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы белән берлектә, түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

2020 елның 10 ноябренә кадәр шәхси ярдәмче хуҗалыклар алып баручы гражданнарга субсидияләр бирү өлешендә «Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 26 гыйнвар, 42 нче карарына үзгәрешләр кертүне;

шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга субсидияләр биргәндә Системаны тәҗрибәи-сәнәгати эксплуатацияләүне үткәрүне.

5. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына Системаны тәҗрибәи-сәнәгати эксплуатацияләүдә катнашуны тәкъдим итәргә.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин